Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы
Уракчы авыл җирлеге составына керүче
Уракчы авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

**КАРАР**

18 ноябрь 2022 ел № 1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2021 елның 18 ноябрендә түбәндәге сораулар буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре белән беркетмә төзелде: “Сез 2023 елда Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Уракчы авыл җирлегенең Уракчы авыл торак пунктында тору урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешесеннән (уку йортларына йөреп укучы студентлардан, беренче торкем инвалидлардан, мобилизацияләнгән гражданнар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан гайре), 400 сум күләмендә үзара салым акчасы кертүгә һәм тупланган средстволарны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтеп түбәндәге эшләрне башкару өчен тотуга ризамы:

-торак пунктлар чикләрендә урамнарны яктырту челтәрләрен тоту (лампалар, яктырткычлар, электр товарлары сатып алу һәм урнаштыру, урам утларын агымдагы ремонтлау һәм аларга хезмәт күрсәтү;

- авыл җирлеге чикләрендә су белән тәэмин итү системасын тәртиптә тоту (суэтем башняларына тирәнлек насослары сатып алу өчен);

- торак пунктлар чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау;

-авыл җирлеге чикләрендә кышкы юлларны карап тоту (кышкы чорда юлларны кардан чистарту-килешү буенча эшләр өчен түләү, ягулык-майлау материаллары сатып алу);

- авыл җирлеге территориясен җәй көне чабу (ягулык-майлау материаллары, трактор һәм аларга комплектлаучылар өчен асылмалы җиһазлар, запас частьләр сатып алу , килешү буенча эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү);

- зиратларны төзекләндерү һәм карап тоту (төзелеш материаллары сатып алу, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү).

“ӘЙЕ” “КАРШЫ”

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 262 кеше, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны 138 кеше кертелгән.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

“ӘЙЕ» позициясе өчен халык җыенында катнашучы 138 кеше тавыш бирде;
«ЮК» позициясе өчен җыенда катнашучы 0 тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены **карар итте**:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Урахча авыл җирлеге составына керүче Уракчы авылында гражданнар җыенын үткән дип, гражданнар җыены нәтиҗәләре - дөрес дип танырга.

2. Гражданнар җыенына куелган түбәндәге сорауны кабул ителгән дип расларга: “Сез 2023 елда Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Уракчы авыл җирлегенең Уракчы авыл торак пунктында тору урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешесеннән (уку йортларына йөреп укучы студентлардан, беренче торкем инвалидлардан, мобилизацияләнгән гражданнар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан гайре) 400 сум күләмендә үзара салым акчасы кертүгә һәм тупланган средстволарны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтеп түбәндәге эшләрне башкару өчен тотуга ризамы:

-торак пунктлар чикләрендә урамнарны яктырту челтәрләрен тоту (лампалар, яктырткычлар, электр товарлары сатып алу һәм урнаштыру, урам утларын агымдагы ремонтлау һәм аларга хезмәт күрсәтү;

- авыл җирлеге чикләрендә су белән тәэмин итү системасын тәртиптә тоту (суэтем башняларына тирәнлек насослары сатып алу өчен);

- торак пунктлар чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау;

-авыл җирлеге чикләрендә кышкы юлларны карап тоту (кышкы чорда юлларны кардан чистарту-килешү буенча эшләр өчен түләү, ягулык-майлау материаллары сатып алу);

- авыл җирлеге территориясен җәй көне чабу (ягулык-майлау материаллары, трактор һәм аларга комплектлаучылар өчен асылмалы җиһазлар, запас частьләр сатып алу , килешү буенча эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү);

- зиратларны төзекләндерү һәм карап тоту (төзелеш материаллары сатып алу, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү).

3. Карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Урахча авыл җирлегенең түбәндәге адреслар буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендларында: Татарстан Республикасы, Балык Бистәсе районы, Уракчы авылы, Совет урамы, 36Айорт; Мельничный Починок авылы, Киров урамы, 20Б йорты Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”ында урнаштырырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Уракчы авыл җирлеге башлыгы: Гәрәев Ф.М